# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ LII- е УТЫРЫШЫ

Шуган ав. 24 март 2025 ел

**К А Р А Р № 87**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районың Шуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Шуган авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, аның график сурәте белән бергә (2 нче кушымта), әлеге карар кабул ителгәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (muslumovo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлегенең Рус Шуганы, Островка, Иске Смыловка, Татар Смыловкасы авыллары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча халыкка җиткерергә:

Рус Шуганы ав., Ленин ур., 18А йорт (мәдәният йорты бинасы);

Островка ав., Урман ур., 5 й. (шәхси йорт);

Иске Смыловка ав., Совет ур., 12 й. (шәхси йорт);

Татар Смыловкасы ав., Ленин ур., 35 йорт (шәхси йорт).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шуган авыл җирлеге башлыгы А .Ю. Басорина